Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 96-2 09.09.2024 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының 2021 елның 19 июлендәге 20-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2022 елның 01 декабрендәге 55-2 номерлы, 2023 елның 1 февральдагы 61-2 номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчкле авыл җирлеге Советына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчкле авыл җирлеге Советының 2021 елның 19 июлендәге 20-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2022 елның 01 декабрендәге 55-2 номерлы, 2023 елның 1 февральдагы 61-2 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 өлешнең 8.11 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.2 8 өлешнең 8.17 пунктында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.17. Муниципаль хезмәткәргә классլы чин бирү турындагы карар, әлеге өлешнең 8.12 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класслы чин бирү турында барлык кирәкле документлар белән бергә орган яисә җирле үзидарәнең класслы чиннар бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына күрсәтмә кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»;

1.3. 10 өлешнең 10.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә::

«12) «РФдә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләргә аңа билгеле булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр)..»;

1.4. 11 өлешнең 11.1 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны узу чорында ялган документлар һәм (яисә) бозылуы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган Белә торып ялган белешмәләр тапшыру йә бозылуы муниципаль хезмәт

вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлмәвен таныклый торган документлар һәм (яисә) белә торып ялган белешмәләр тапшырмау;»;

1.5. 14 өлешнең 14.5 пунктына «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш»сүзләрен өстәргә.;

1.6. 14 өлешнең 14.7 пунктында «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш»сүзләрен өстәргә.;

15 өлешнең 15.7 пунктында «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.8. 15 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 15.7.1 пункт өстәргә:

«15.7.1. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләрне тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

1.9. 16 өлешнең 16.3 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;

1.10. 26 өлешнең 26.3 п.1 пунктчасында « яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясе вәкаләтле вәкиле тарафыннан» сүзләрен өстәргә;";

1.10.27 өлешнең 27.2 пунктындагы 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«11) муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны узу чорында граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү; ».

1.11. 27 өлешнең 27.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 15 пунктча өстәргә::

«15) дәүләт сере булып торган белешмәләргә билгеләнгән рәвештәге рөхсәтне рәсмиләштерү».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм httr хокукый мәгълүматның рәсми порталында://pravo.tatarstan.ru рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ